| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>СТАРОМЕНЗЕЛЯБАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ МИНЗӘЛӘБАШ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 12 ноябре № 9

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 21 мартындагы 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Минзәләбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Иске Минзәләбаш авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 21 мартындагы 4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.салым түләүчеләр - оешмалар тарафыннан салым аванс белән, узган хисап чорыннан агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталы узганнан соң, җир кишәрлегенең кадастр бәясе процентының тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә түләнә. Салым чоры нәтиҗәләре буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 1 мартыннан да соңга калмыйча түләнә».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3.«Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин рәсми басылган көннән бер айдан да иртәрәк түгел».

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Минзәләбаш авыл җирлеге
Советы Рәисе: А.Н.Габдрахманов